**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
п. Мысовский, ул.Центральная, д.33 а
тел:89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Мысовский поселок, Центральная ур, 33 а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

---

**2024елның 14 феврале** **5 номер**

**КАРАР**

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2018 елның 12 ноябрендәге 36 номерлы Көек авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2022елның 07 ноябрендәге карары үзгәрешләре белән)**

Россия Федерациясе Конституция судының 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы карары, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон (2022 елның 29 декабренә үзгәрешләр белән) нигезендә, карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»2018 елның 12 ноябрендәге 36 номерлы Көек авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертергә:

128.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләре өчен, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларга стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылмаска тиеш.;

3 пунктның 17 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Көек**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.М.Сатдинова**